ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 572-151/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2024 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 №10-101/кс карарына үзгәреш кертү һәм эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 №10-101/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 елга үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе тарафыннан ташландык су агызу өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү буенча җайга салына торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә һәм эчә торган суга озак сроклы тарифларга төзәтмә кертү һәм 2023-2024 елларга җайга

салынулы оешманың кирәкле тулай keremen үзгәртү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2024 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өчен 2020-2024 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2019 №10-101/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.11.2020 №213-70/кс-2020, 17.11.2021, №298-55/кс-2021 карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «һәм ташландык су агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «агынты суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «агынты суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «юынтык суларны агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче кушымтада:

таблицаның 1.1 пунктчасында:

әлеге графаларны

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2022 башлап<br>30.06.2022 кадәр | 19,82 | 8,63 |
| 01.07.2022 башлап<br>31.12.2022 кадәр | 24,11 | 10,02» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

әлеге графаларны

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап<br>30.06.2023 кадәр | 22,61 | 9,60 |
| 01.07.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 22,61 | 9,60 |
| 2024 елның 1 гыйнварыннан<br>2024 елның 30 июненә кадәр | 22,61 | 9,60 |
| 01.07.2024 башлап<br>31.12.2024 кадәр | 23,92 | 10,18» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01.01.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 26,60 |
| 2024 елның 1 гыйнварыннан<br>2024 елның 30 июненә кадәр | 24,98 |
| 01.07.2024 башлап<br>31.12.2024 кадәр | 24,98» |

таблицаның 1.2 пунктында:

әлеге графаларны

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2022 башлап<br>30.06.2022 кадәр | 16,52 | 7,19 |
| 01.07.2022 башлап<br>31.12.2022 кадәр | 20,09 | 8,35» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

әлеге графаларны

| | | |
|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап<br>30.06.2023 кадәр | 18,84 | 8,0 |
| 01.07.2023 башлап | 18,84 | 8,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 31.12.2023 кадәр | | |
| 2024 елның 1 гыйнварыннан<br>2024 елның 30 июненә кадәр | 18,84 | 8,0 |
| 01.07.2024 башлап<br>31.12.2024 кадәр | 19,93 | 8,48» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01.01.2023 башлап<br>31.12.2023 кадәр | 22,17 |
| 2024 елның 1 гыйнварыннан<br>2024 елның 30 июненә кадәр | 20,82 |
| 01.07.2024 башлап<br>31.12.2024 кадәр | 20,82» |

2 нче кушымтада:

атамасында «һәм ташландык су агызу» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 пунктны көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев